**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге Ык торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**«01» декабрь 2020 ел** **№1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 1 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

1) Ык торак пунктындагы Яшел урамында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү).;

2) Ык торак пунктында урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү);

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 90 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 47 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 47 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында халык җыены узган, нәтиҗәләре дөрес дип санарга.

2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ык торак пункты территориясендә һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда үзара салым кертүгә 400 сум күләмендә акча кертү белән килешәсезме?:

1) Ык торак пунктындагы Яшел урамында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү).;

2) Ык торак пунктында урам утлары объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү) - карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Җыелышның нәтиҗәләрен Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы

Р.М.Галимов